**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең «Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең «Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2023 елның 26 октябрендәге 738 номерлы Указының 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) беренче абзацта «затлардан» сүзен «хәрби хезмәткәрләрдән» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «Россия Федерациясе гражданнары өчен социаль ярдәм чарасы буларак 305 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пунктында (1 разрядлы) сайлап алынган һәм әлеге контрактны төзегән датага Россия Федерациясе Оборона министрлыгы хәрби частьләрендә хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәт узган Россия Федерациясе гражданнары өчен социаль ярдәм чарасы буларак 305 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләргә.».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 28 октябрь
№ 745